ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.04.2016 г. Казань № 122-12

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" № 273-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге "Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" № 650 Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгына (Гатауллина А.Ф.):

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе аппаратындагы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук гражданнарны алар белән хезмәт контрактларын төзегәндә шушы боерык белән таныштырырга;

Тәртипне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Ветеринария эшен оештыру бүлеге башлыгына (Хәлиуллин М.Ф.) шушы боерыкны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең "Интернет" мәгълүмати-

телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми порталында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе сайтының "Коррупциягә каршы көрәш" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе
башлыгы – Татарстан Республикасының
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г. Хисаметдинов

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе
башлыгының 2016 елның
25 апрелендәге №122-п
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә (алга таба – Ветеринария идарәсе) аларга карата Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы (алга таба – Ветеринария идарәсе башлыгы) эшкә алучының вәкиле булып торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре) тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен регламентлый.

2. Хәбәр гражданлык хезмәткәре тарафыннан шушы Тәртипкә карата Кушымтада китерелгән вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә (алга таба – белдерүнамә) рәвешендә язмача төзелә һәм Ветеринария идарәсе башлыгына җибәрелә

3. Ветеринария идарәсе башлыгы өч эш көне дәвамында белдерүнамәне коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) беренчел карап тикшерү өчен җибәрә.

4. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү барышында җаваплы зат белдерүнамәне җибәргән гражданлык хезмәткәреннән анда бәян ителгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрүнең инициаторы булырга хокуклы.

5. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли. Беренчел карап тикшерү барышында алынган белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат белдерүнамәне алган көннән башлап җиде эш көне дәвамында аның тарафыннан Ветеринария идарәсенең дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Шушы Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәргән очракта, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан Комиссия рәисенә белдерүнамәне алган көннән соң 45 көн дәвамында тапшырыла. Аталган

вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.

7. Белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Ветеринария идарәсе боерыгы белән раслана торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә нигезендә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә карата кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы А.Г. Хисаметдиновка

кемнән___________________________
(вазифасының аталышы)
_________________________________
_________________________________
_________________________________
(Ф.И.А., адресы, телефон номеры)

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган (*кирәклесенең астына сызарга*) шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү өчен нигез булган шартлар:______
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларның үтәлешенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вазифаи вәкаләтләр:________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________
______________________________________________________________________

Шушы белдерүнамәне карап тикшергәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр

каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим / ниятләмим (*кирәклесе астына сызарга*).

| | | |
|---|---|---|
| ___________ | _____________ | ___________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |